**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2019 елның 18 декабрендәге №209

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясына, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 18 номерлы карары (Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 165 номерлы, 2019 елның 12 ноябрендәге 202 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының» «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге Карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына

бюджетлардан башлап, бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://pravo.tatarstan.ru)Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70 нчы йорт (җирлекнең административ бинасы), Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче май ур., 30 нчы йорт, «Гадел» кибете янында мәгълүмат тактасы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., вокзал алды мәйданчыгында мәгълүмат стенды, Кузнечная ур., 13 а йорт, «Диана» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Кузнечная ур., 16 а йорт, «Рубин» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Б.Кочемирская ур., 2а, «ЮСОН» кибете янында мәгълүмат стенды, Протоповка авылы, Кооператив урамы, 15 нче йорт, ИП Яфизов кибете янында мәгълүмат тактасы, Олы Ходяшево авылы, Үзәк урам, 42 нче йорт, ИП Навасардян кибетендә мәгълүмат тактасы.

Җирлек башлыгы,
Совет Рәисе Ю. М. Некрасова

Карамалы Тау шәһәр җирлеге советының 2019 елның 18 декабрендәге №209 Карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы (Алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен (алга таба – субсидияләр, җирлек) финанслашу максатларында түбәндәге очракларда бирелә:

- җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәүгә субсидияләр бирүгә ихтыяҗы булу;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетының үз акчалары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелгән сценар алымнар кысаларында исәпләнгән «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чыгымнарыннан артып китүе;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетының өстәмә керемнәре исәбеннән акча бирү, шулай ук агымдагы финанс елы башына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты счетында калган акчалар һәм (яисә) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетында экономия булганда ассигнованиеләрне яңадан бүлү исәбеннән акчалар бирү;

- законнарда каралган башка очраклар.

2. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының тиешле финанс елына һәм план чорына «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карары белән раслана.

4. Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып тора.

5. Субсидия бирүнең максатлары һәм шартлары авыл җирлеге башкарма комитеты һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән җирлек башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны сарыф итү шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм сарыф итү өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

ж) килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

7. Килешү проектын әзерләү Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешүгә Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.

9. Субсидия алу өчен муниципаль берәмлек Башкарма комитеты килешүдә билгеләнгән вакытта, Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

Карамалы Тау шәһәр җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә гариза;

килешүдә билгеләнгән башка документлар.

10. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме килешүдә күрсәтелгән формула буенча билгеләнә.

11. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр муниципаль берәмлекләр бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачыкланган территориаль органнары счетына килешүдә билгеләнгән срокларда күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 гыйнварына файдаланылмый калган субсидияләр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын законнар нигезендә җирлек башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары контрольдә тота.